КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 18 март г.Казань № 157

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, аларны реализацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2008 ел, 16 май, 326 нчы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, аларны реализацияләү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, аларны реализацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2008 ел, 16 май, 326 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 29 август, 619 нчы; 2009 ел, 15 июнь, 394 нче; 2011 ел, 20 декабрь, 1021 нче; 2013 ел, 11 июнь, 398 нче; 2016 ел, 27 июнь, 443 нче; 2016 ел, 27 июль, 515 нче; 2016 ел, 5 декабрь, 891 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 806 нчы; 2019 ел, 9 август, 660 нчы; 2020 ел, 24 февраль, 131 нче; 2020 ел, 6 март, 172 нче; 2021 ел, 14 гыйнвар, 9 нчы; 2022 ел, 29 март, 281 нче; 2022 ел, 26 август, 912 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, аларны реализацияләү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

37 пунктта «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (СТИБДМС)» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – БЦП)» сүзләренә алмаштырырга, «СТИБДМС» аббревиатурасын «БЦП» аббревиатурасына алмаштырырга;

38 пунктта «СТИБДМС» аббревиатурасын «БЦП» аббревиатурасына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин